КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 декабрь г.Казань № 1211

2020 елда фондның оештыру-хокукый формасында унитар коммерциячел булмаган оешмалар төзегәндә Татарстан Республикасы бюджетыннан мөлкәти кертем рәвешендә субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2020 елда фондның оештыру-хокукый формасында унитар коммерциячел булмаган оешмалар төзегәндә Татарстан Республикасы бюджетыннан мөлкәти кертем рәвешендә субсидияләр бирү кагыйдәләрен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 28 декабрь, 1211 нче
карары белән расланды

2020 елда фондның оештыру-хокукый формасында унитар коммерциячел булмаган оешмалар төзегәндә Татарстан Республикасы бюджетыннан мөлкәти кертем рәвешендә субсидияләр бирү кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булып тормаган коммерциячел булмаган оешмаларга фондның оештыру-хокукый формасында унитар коммерциячел булмаган оешмалар төзегәндә мөлкәти кертем кертү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын (алга таба - субсидия) билгелиләр.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына (алга таба - Министрлык) 2020 елга субсидия бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидияләр алучылар - аларга карата Татарстан Республикасы исеменнән Министрлык гамәлгә куючы булып торган фондның оештыру-хокукый формасында коммерциячел булмаган унитар оешмалар (алга таба - коммерциячел булмаган оешма), шул исәптән:

Өлешле төзелештә катнашучы гражданнарның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы фонды;

Татарстан Республикасында төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм фонды.

4. Коммерциячел булмаган оешмага бирелә торган субсидия күләме «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында" 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

5. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә:

коммерциячел булмаган оешманың салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы юк;

коммерциячел булмаган оешманың Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне кире кайтару буенча вакыты чыккан, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты каршында акчалата йөкләмәләр буенча вакыты чыккан (җайга салынмаган) бурычлары юк;

коммерциячел булмаган оешма үзгәртеп кору, бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, коммерциячел булмаган оешма эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

коммерциячел булмаган оешма әлеге Кагыйдәләрнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый.

6. Субсидия алу өчен коммерциячел булмаган оешма Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

субсидия бирү турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган ирекле рәвештә язылган гариза (алга таба - гариза);

коммерциячел булмаган оешманың гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турында документларныңкоммерциячел булмаган оешманың вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган күчермәләре;

әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе яисә башка вәкаләтле зат имзасы куелган белешмә (ирекле формада);

коммерциячел булмаган оешма җитәкчесенең вәкаләтләрен раслый торган документларның коммерциячел булмаган оешманың вәкаләтле заты тарафыннан таныкланган күчермәләре.

Документлар кәгазьдә һәм (яисә) электрон чыганакларда бирелергә мөмкин.

7 Коммерциячел булмаган оешма үз теләге белән Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазенең күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

салым органыннан салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау турында белешмә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бу пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Коммерциячел булмаган оешма тапшырылган документларның һәм әлеге Кагыйдәләрнең 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплы.

Министрлык гаризаны теркәлгән документлары белән кабул итүне һәм кергән көнендә теркәүне гамәлгә ашыра.

Гаризаны кабул иткән һәм теркәгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә Министрлык гаризаны комплектлылыкка, булган белешмәләрнең тулылыгына һәм әлеге Кагыйдәләрнең 5 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә әлеге Кагыйдәләрнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган документларның булу-булмавына тикшерә.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлык субсидия бирү турында яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Коммерциячел булмаган оешмага субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү;

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта Министрлык бу хакта субсидияне алучыга Министрлык тарафыннан субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән соң ике көн эчендә хәбәр итә.

11. Субсидия бирү Министрлык һәм коммерциячел булмаган оешма (алга таба - килешү) арасында субсидия бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

аны күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе;

субсидиядән файдалану турында хисап бирү сроклары һәм рәвешләре, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисаплылык һәм өстәмә хисаплылык (кирәк булганда);

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт;

коммерциячел булмаган оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм Кагыйдәләрен үтәүне Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

Кирәк булганда, Министрлык һәм коммерциячел булмаган оешма Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча шартнамәгә өстәмә килешү, шул исәптән шартнамәне өзү турында өстәмә килешү төзи.

12. Субсидия бирү нәтиҗәсе - коммерциячел булмаган оешманың югары коллегиаль органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланган коммерциячел булмаган оешманың эшчәнлек планын үтәү.

13. Министрлык субсидияне субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына килешү төзелгән көннән соң 10 эш көне эчендә бер тапкыр күчерә.

14. Коммерциячел булмаган оешма әлеге Кагыйдәләрнең 12 пунктында күрсәтелгән субсидияне бирү нәтиҗәсенә ирешү турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең үрнәк формасы буенча Министрлыкка, субсидия алынган елдан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, хисап бирә.

15. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары әлеге Кагыйдәләрдә һәм килешүдә билгеләнгән коммерциячел булмаган оешмага субсидия бирү максатларының, шартларының һәм тәртибенең үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыралар.

16. Субсидия коммерциячел булмаган оешма тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тикшерүләре фактлары буенча ачыкланган шартлар коммерциячел булмаган оешма тарафыннан бозылганда;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү.

17. Коммерциячел булмаган оешма тарафыннан әлеге Кагыйдәләрнең 16 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакыты бозылганда Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

18. Бирелгән субсидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.